## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы

## КАРАРЫ

**№30** **24 07.2026 ел**

Зәй муниципаль районы Бигеш
авыл җирлеге Советының "Татарстан
Республикасы Зәй муниципаль районы
Бигешавыл җирлеге муниципаль
мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм
шартлары турындагы нигезләмәне раслау
хакында" 28.12.2020 № 23 карарына үзгәрешләр
кертү турында

««Конкуренцияне яклау» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 29 декабрендәге 577-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәме раслау хакында» 28.12.2020 № 23 карарына (Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 20.04.2021 ел №30, 15.03.2022 ел № 58, 23.11.2022 № 80, 02.03.2023 № 99, 15.10.2024 № 148, 30.06 .2025 № 182 карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Шушы Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта аукцион җиңүчесе йә аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат белән сату-алу килешүе төзү "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта аукцион йомгаклары турында беркетмә урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Муниципаль мөлкәтне гавами сервитут һәм (яки) 21.12.2001 № 178-ФЗ Федераль законда һәм (яки) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләгән очракта, аукционда төзелә торган мондый мөлкәтне сату-алу шартнамәсенең мөһим шарты булып сатып алучының әлеге йөкләмәнең шартларын үтәү бурычы тора.»;

1.2. 6.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Гавами тәкъдим ярдәмендә сатуда җиңүче белән сату-алу шартнамәсе төзү гавами тәкъдим ярдәмендә мөлкәтне сату йомгаклары турында беркетмә "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет Рәисе** **А.В. Камилов.**